**КАРАР № 53**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Советы утырышы**

**29 август 2022 ел** **Яңа Шашы авылы**

**Яңа Шашы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын раслау турында " 2013 елның 3 июнендәге 68 нчы номерлы карарын гамәлдән чыгару турында (2017 елның 22 мартындагы 46 номерлы карар редакциясендә).**

Татарстан Республикасы Әтнә район Советының “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Яңа Шашы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында” гы 2022 елның 9 февралендә кабул ителгән 113 нче номерлы карары нигезендә, Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын раслау турында " 2013 елның 3 июнендәге 68 нчы номерлы карарын;

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 22 мартындагы 46 нче номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы М.С.Сабирҗанов